РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422612, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422612, РТ, Лаеш район, Мысовский
поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**2022 елның« 11 » октябре** **36 номер**

**КАРАР**

**Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында**

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Көек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 апрелендәге 4 номерлы «Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 апрелендәге 4 номерлы «Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларына карап, 2020 елның 1 октябреннән күтәрергә.
3. Көек авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.
4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге муниципаль

берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Көек авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.М. Сатдинова**